| | | |
|---|---|---|
| **СОВЕТ БИКБУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗƏЛƏ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИКБАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

РЕШЕНИЕ КАРАР

**2019 ел, 17 ноябрь** **№ 1**

**Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлеге составына кергән Бикбау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ нең 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы №45-ЗРТ Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 17 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар түбәндәге мәсьәлә буенча җыен беркетмәсе төзелде: “2020 елда Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Бикбау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (1 нче төркем инвалидлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, кайнар нокталарда хезмәт итүчеләр һәм аларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?”

- Бикбау авылында яңа скважина казыту (эшләр өчен килешү буенча түләү)
- Бикбау авылының Ленин урамы тыкырыкларына су линиясе үткәрү (6 тыкырык) (торбалар сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 373 гражданнар җыенында катнашучы кертелгән , тавыш бирүдә катнашучы гражданнар җыенында катнашучылар саны 189 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе” позициясе өчен 178 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде;

“Юк” позициясе өчен 11 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Бикбау торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – гамәлдә дип танырга.

2. “2020 елда Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Бикбау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (1 нче төркем инвалидлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, кайнар нокталарда хезмәт итүчеләр һәм аларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?” мәсьәләсе буенча карарны танырга:

   - Бикбау авылында яңа скважина казыту (эшләр өчен килешү буенча түләү)

   - Бикбау авылының Ленин урамы тыкырыкларына су линиясе үткәрү (6 тыкырык) (торбалар сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Бикбау авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, Минзәлә муниципаль районы сайтында: http://menzelinsk.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы һәм http://pravo.tatarstan Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматенең рәсми порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Гамәлдәге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенә җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ______ Л.Н.Мардамшина

Бикбау авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе ______ Л.Н.Мардамшина

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Бикбау торак пунктында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 ел, 17 ноябрь № 1

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131-ФЗ нең 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы №45-ЗРТ Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 17 ноябрендә Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Бикбау торак пунктында узган гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2020 елда Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Бикбау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (1 нче төркем инвалидлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, кайнар нокталарда хезмәт итүчеләр һәм аларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Бикбау авылында яңа скважина казыту (эшләр өчен килешү буенча түләү)
- Бикбау авылының Ленин урамы тыкырыкларына су линиясе үткәрү (6 тыкырык) (торбалар сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү)

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ____ Л.Н.Мардамшина

Бикбау авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе ____ Л.Н.Мардамшина